Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы
Зур Тигәнәле муниципаль бюджет төп гомумбелем бирү мәктәбе

| “Каралды” | “Килешенде” | “Расланды” |
|---|---|---|
| ММБ җитәкчесе | Зур Тигәнәле төп белем бирү мәктәбе укыту - тәрбия эшләре буенча директор урынбасары | Зур Тигәнәле төп белем бирү мәктәбе директоры |
| /Ахметзянова И.Р./ | /Сунаева Л.Х./ | /Сайфутдинова А.Н./ |
| Беркетмә №1, 26.08.2022 | 31.08.2022 | Приказ № 131 от 31.08.2022 |

# 2022-2023 нче уку елы өчен кечкенәләр төркеменә перспектив план

Төзеделәр:
Хайбуллина Энҗе Нәбиулловна.
Мустафина Эльмира Ринатовна.

Педагогик киңәшмә
утырышында кабул ителде
Беркетмә №1, 31.08.2022

2022

# Эчтәлек

1. Тәрбиячеләр турында белешмә............................................................................ 3

2. Аңлатма язуы.................................................................................................... 4

3. Тәрбия бурычлары.......................................................................................... 5

4. Якынча көндәлек режим.................................................................................. 6

5. Җәйге чорга көндәлек режим......................................................................... 6

6. Турыдан туры белем бирү эшчәнлеге............................................................ 7

7. Турыдан- туры белем бирү эшчәнлегенең көн дәвамында кулланышы..............7

8. Балаларның мөстәкыйль эшчәнлеге.................................................................8

9. Психологик- педагогик эшнең эчтәлеге..........................................................8

10. Танып белү. Иң гади математик кузаллауларын үстерү...................................11

11. Аралашу ( сөйләм телен үстерү).....................................................................14

12. Танып белү. (Әйләнә тирә белән танышу)....................................................... 18

13. Социальләштерү............................................................................................ 22

14. Хезмәт. ........................................................................................................24

15. Сынлы сәнгать эшчәнлеге. Рәсем....................................................................28

16. Сынлы сәнгать эшчәнлеге. Әвәләү...................................................................31

17. Сынлы сәнгать эшчәнлеге. Кисеп ябыштыру....................................................35

18. Тормыш иминлеге ...........................................................................................36

19. Әти - әниләр белән эш .....................................................................................40

20. Программа үтәлешен йомгаклау нәтиҗәләре ...................................................42

21. Милли төбәк компоненты куллану (НРК).........................................................45

22. Кулланылган әдәбият.........................................................................................47

## *Тәрбиячеләр турында белешмә*

1. **Хайбуллина Энҗе Нәбиулловна**

- **Белеме** - Яр Чаллы дәүләт педагогия институты.
- **Эш стажы** – 36ел
- **Категориясе** - 1нче категория.

2. **Мустафина Эльмира Ринатовна** .

- **Белеме** - Татар дәүләт гуманитар-педагогия университеты.
- **Эш стажы** - 32 ел.
- **Категориясе** - 1нче категория.

## Аңлатма язуы

Әлеге программа Н.Е.Вераксы, Т.С. Комарова, М. А. Васильевалар тарафыннан төзелгән “Туганнан алып мәктәпкәчә” программасына таянып төзелгән.

Белем бирүнең беренче баскычы булган мәктәпкәчә тәрбия учреждениеләренең эше көннән - көн яңара, матур традицияләргә байый. Педагоглар яшь буынны тәрбияләүдә яңа чаралар, белем бирүнең нәтиҗәле методларын эзлиләр, тәрбия эшендә халкыбызның күркәм традицияләренә, педагогик тәҗрибәсенә ныграк таяналар. Балаларның физик, интеллектуаль һәм шәхси үсешен тәэмин итү, иҗат мөмкинлекләрен ачу һәм үстерүгә зур игътибар бирелә.

Балалар бакчаларының эшен камилләштерү Һәм эчтәлеген яңарту буенча үзгәрешләр кертелгән бу программа, мәктәпкәчә тәрбия учреждениеләре алдында түбәндәге бурычларны куя:

- Балаларның сәламәтлеген саклау, аларның физик һәм психик үсешен тәэмин итү;
- Тәрбия – белем бирү эшен гуманлаштыру;
- Халык традицияләренә милли гореф гадәтләргә нигезләнеп балаларда әхлакый сыйфатлар тәрбияләү;
- Балаларның сәләтләрен ачу, юнәлеш бирү һәм үстерү өчен шартлар тудырып, нык белемле, зирәк акыллы шәхес формалаштыру.

Әлеге бурычларга ирешү эшчәнлекнең төрле вакытларында алып барыла:

- Белем бирү эшчәнлеге (уен, аралашу, хезмәт, музыкаль, уку)
- Балаларның көндәлек эшчәнлеге;
- Балаларның мөстәкыйль эшчәнлеге;
- Программаны тормышка ашыру максатыннан ата - аналар белән даими эш.

Программа тарафыннан кулланган бурычларны тормышка ашыру белем бирү эшчәнлеге вакытында гына түгел, ә әлеге балалар бакчасы эчендәге үзенчәлекләргә таянып төзелгән көндәлек эшчәнлек вакытында да алып барыла.

Эш программасның эчтәлеге – физик, социаль, танып белү, аралашу, сынлы сәнгать юнәлешләре буенча, шәхси һәм яшь үзенчәлекләрен күздә тотып, балага тәрбия һәм белем бирүдә юнәлтелгән эшчәнлек төрләрен үз эченә ала.

## *Тәрбия бурычлары*

Организмнарын даими рәвештә чыныктыру, шөгыльләрдә, шулай ук башка вакытта төп хәрәкәт төрләрен башкару осталыкларын һәм күнекмәләрен формалаштыру һәм камилләштерү, матур гәүдә, шулай ук гигиена күнекмәләре тәрбияләү өчен шартлар тудырып, балаларның сәламәтлекләрен ныгыту һәм саклануын дәвам иттерү; көндәлек режимны төгәл үтәү. Балаларның пространствода ориентлаша белүләрен камилләштерү. Күмәк уеннарда һәм физик күнекмәләрдә катнашуга дәртләндерү.

Мөстәкыйль хәрәкәт эшчәнлекләрендә уңай эмоцияләр, активлык формалаштыруга булышлык итү.

Әйләнә-тирәсендәге кешеләрнең тормышы һәм эшчәнлеге, табигать күренешләре белеп кызыксыну, тирә-юнендәге предметлар һәм күренешләргә игътибар туплый белүне тәрбияләү.

Предметлар һәм күренешләр арасындагы бәйләнешләрне аңларга һәм шуның аша гади генә нәтиҗәләр чыгарырга белергә өйрәтү.

Өлкәннәр хезмәтенә уңай мөнәсәбәт формалаштыру. Көченнән килгән кадәр хезмәткә катнашу теләген уяту, кечерәк кыенлыкларны җиңә белергә өйрәтү.

Балаларның дөрес сөйләмнәренә: сүзлек составларын баетуга, җөмләләрне төзи белүләренә, сүзләрне дөрес һәм ачык итеп әйтүләренә ирешү.

Әдәби әсәрене азаккача тыңлый, әсәрләрдәдә вакыйгаларның ничек үрелеп баруын күзәтә белү сыфаты тәрбияләү.

Балаларның музыкаль сәләтләрен үстерү, музыканың яңгырашындагы үзгәрешләрне тоя белергә өйрәтү.

Балалар бакчасында, өйдә, урамда, бердәм тәртип күнекмәләрен ныгыту.

Нәрсә яхшы һәм нәрсә начар булуы турында иң гади кузаллау формалаштыруны дәвам иттерү.

Балаларда әйләнә-тирәнең матурлыгына, сәнгать әсәрләренә эстетик караш тәрбияләү.

## *Якынча көндәлек режим*

| *Эшчәнлекнең төре* | ВАКЫТЫ |
|---|---|
| Балаларны кабул итү | 7.30 – 8.00 |
| Гигиена чаралары, иртәнге ашка хәзерлек, иртәнге аш. | 8.00 – 8.45 |
| Уеннар, ТББЭнә хәзерлек. | 8.45 – 9.00 |
| ТББЭ | 9.00 - 9.15 - 9.30 |
| Мөстәкыйль уеннар | 9.30 – 10.00 |
| Икенче иртәнге аш | 10.00 -10.20 |
| Урамга чыгуга хәзерлек | 10.20 – 10.30 |
| Саф һавага чыгу | 10.30 – 11.30 |
| Урамнан керү,гигиена чаралары,төшке ашка хәзерлек | 11.30 – 11.45 |
| Төшке аш | 11.45 – 12.20 |
| Гигиена чаралары, йокыга хәзерлек. | 12.20 – 12.30 |
| Көндезге йокы | 12.30 – 15.00 |
| Йокыдан уяну,чыныктыру чаралары. | 15.00 – 15.15 |
| Төштән соңгы аш. | 15.15 – 15.30 |
| Шәхси эш,аз хәрәкәтле уеннар, мөстәкыйль эшчәнлек. | 15.30 – 16.00 |
| Мөстәкыйль эшчәнлекләре,уеннар.Балаларны өйгә озату | 16.00 – 16.30 |

## ***Җәйге чорга көндәлек режим***

| ***Эшчәнлекнең төре*** | ***Вакыты*** |
|---|---|
| Урамда:балаларны кабул итү, уеннар, иртәнге гимнастика | 7.30-8.20 |
| Иргәнге ашка хәзерлек,иртәнге аш | 8.20-8.55 |
| Уеннар, мөстәкыйль эшчәнлек, урамга чыгарга хәзерлек | 8.55-9.35 |
| Урамда:шөгыльләр, уеннар, күзәтү, мөстәкыйль эшчәнлек, һава кояш процедуралары. | 9.35-11.15 |
| Урамнан керү, гигиена чаралары | 11.20-11.45 |
| Көндезге ашка хәзерлек, ашау вакыты | 11.45-12.20 |
| Йокларга эзерләнү, көндезге йокы | 12.20-15.00 |
| Йокыдан уяну,чыныктыру чаралары,төштән соңгы аш | 15.00-15.35 |
| Мөстәкыйль эшчәнлек, уеннар | 15.35-16.00 |
| Урамда, балаларны өйгә озату | 16.00-16.30 |

## *Турыдан туры белем бирү эшчәнлеге*

| **Эшчәнлекнең төре** | **Күләме** | **Белем бирү өлкәсенең интеграциясе** |
|---|---|---|
| Физик тәрбия | Атнага 2 тапкыр | “Сәламәтлек”, “Тормыш иминленген саклау”, ”Хезмәт”. “Аралашу”, “Музыка”, |
| Танып белү(ФЭМП)<br>Әйләнә-тирә белән танышу | Атнага 1 тапкыр<br>Атнага 1 тапкыр | “Танып белү”, ”Хезмәт”, “Социальләштерү”, Сынлы сәнгать эшчәнлеге”, “Аралашу” |
| Сөйләм телен үстерү<br>Матур әдәбият уку | Атнага 1 тапкыр<br>Атнага 1 тапкыр | “Тормыш иминлеген саклау”, “Социальләштерү”, ”Хезмәт”, “Аралашу”, ”Матур әдәбият белән танышу”, “Музыка”. |
| Сынлы сәнгать<br>• Рәсем<br>• Әвәләү<br>• Кисеп ябыштыру<br>• Конструкцияләү | 2 атнага 1 тапкыр<br>2 атнага 1тапкыр | ”Сынлы сәнгать эшчәнлеге”, “Аралашу”, “Танып белү”, ”Хезмәт”. |
| Музыка | Атнага 2 тапкыр | “Физик тәрбия”, “Аралашу”, “Танып белү”. |

## *Турыдан- туры белем бирү эшчәнлегенең көн дәвамында кулланышы*

| Режим вакыты | Вакыты | Белем бирү өлкәсенең интеграциясе |
|---|---|---|
| Иргәнге гимнастика | Көн саен | “Физик тәрбия”, “Сәламәтлек”, “Тормыш иминлеген саклау”, “Музыка”. |
| Чыныктыру чаралары | Көн саен | “Сәламәтлек”, “Тормыш иминлеген саклау”, “Социальләштерү”, “Аралашу”. |
| Гигиена чаралары | Көн саен | “Сәламәтлек”, “Тормыш иминлеген саклау”, “Социальләштерү”, “Аралашу”. |
| Көн дәвамында үткәрелә торган әңгәмәләр | Көн саен | “Танып белү”, “Аралашу”, “Сәламәтлек”, “Тормыш иминлеген саклау”, |

| | | |
|---|---|---|
| | | “Социальләштерү”. |
| Матур әдәбият белән танышу | Көн саен | “Аралашу”, ”Сынлы сәнгать эшчәнлеге”, “Музыка”. |
| Кизү тору | Көн саен | ”Хезмәт”, “Сәламәтлек”, “Тормыш иминлеген саклау”, “Социальләштерү”, “Аралашу”. |
| Урамда | Көн саен | “Сәламәтлек”, “Физик тәрбия”, “Тормыш иминлеген саклау”, “Аралашу”, “Социальләштерү”, “Танып белү”. |

## ***Балаларның мөстәкыйль эшчәнлеге***

| Эшчәнлекнең төре | Вакыты | Белем бирү өлкәсенең интеграциясе |
|---|---|---|
| Уен | Көн саен | “Сәламәтлек”, “Физик тәрбия”, “Тормыш иминлеген саклау”, “Аралашу”, ”Сынлы сәнгать эшчәнлеге”, “Музыка”, “Социальләштерү”,”Хезмәт”, ”Матур әдәбият белән танышу”, “Танып белү”. |
| Активлык почмакларда балаларның мөстәкыйль эшчәнлеге | Көн саен | “Сәламәтлек”, “Физик тәрбия”, “Тормыш иминлеген саклау”, “Аралашу”, ”Сынлы сәнгать эшчәнлеге”, “Музыка”, “Социальләштерү”,”Хезмәт”, ”Матур әдәбият белән танышу”, “Танып белү”. |

# ***Психологик- педагогик эшнең эчтәлеге***

### ***Сәламәтлек***

**Максат**: балаларның сәламәтлеген саклау, ныгыту; сәламәт яшәү рәвеше нигезләре белән таныштыру. Сәламәт яшәү рәвеше турында күзаллау булдыру.

| ***Ай*** | ***Физик эчшәнлеге*** | ***Культура гигиена күнекмәләре тәрбияләү*** | ***Сәламәт яшәү рәвеше турында күзаллау булдыру*** |
|---|---|---|---|

| | | | |
|---|---|---|---|
| Сентябрь | Медицина хезмәткәрләре күзәтчелегендә, һава, кояш, судан файдаланып, чыныктыру чаралары комплексы уздыру. | Балаларны пөхтәлеккә, тышкы кыяфәтен тәртиптә тотарга күнектерү. | Диагностика.<br>Әңгәмә " Кеше әгъзалары" 12б.(3) Шигырь " Утыр балам ашарга" 55б.(4)<br>"Чыныктыру" әти әниләр өчен мәгълүмат. |
| Октябрь | Бина эчендә җиңел киенеп йөрергә күнектерү.<br>Көндәлек режимга ярашлы рәвештә саф һавада йөрү. | Кул- битне мөстәкыйль рәвештә чиста итеп юарга, сабын, тарактан дөрес файдаланырга, юынганнан соң сөртенергә, сөлгене урынына элеп куярга. | Әңгәмә " Шәхси гигиена әйберләрен дөрес куллану" 64б.(5)<br>Уен "Ашамлыкны дөрес әйт"13б.(6)<br>Рәсемнәр буенча сөйләшү " Көн тәртибе"<br>Шигырь " Беренче рәхмәт" 55б.(4) |
| Ноябрь | Һәр көнне 5-6 минутлык иртәнге гимнастика үткәрү. | Кирәк булганда кулъяулыктан файдаланырга, тешләрне чистартыра гадәтләндерү. | Әңгәмә " Киенү һәм чишенү әдәбе" 65б. (5)<br>Уен "Күрсәт әле үскәнем" 329б.(7)<br>Әти-әниләр өчен мәгълүмат "Куркынычсызлыкны ничек булдырмаска"<br>Табышмаклар. |
| | Һавада йөргәндә хәрәкәтле күмәк уеннарда һәм физик күнегүләрдә катнашырга, шөгыльләрдән тыш вакытларда физкультура җиһазларыннан файдаланырга өйрәтү | Ашау күнекмәләре формалаштыру: ипине вакламаска, азыкны түкми- чәчми ашарга, ашаганда авызны чәпелдәтмәскә, кашык, чәнечке, салфеткадан дөрес файдаланырга күнектерү. | Рәсемнәр буеча әңгәмә: "Гөмбәләр"<br>Уен " Иртәнге күнегүләр" 277б.(7)<br>С/р уен " Аюны табибка алып барабыз" |
| | | Ризык капкан килеш сөйләшү, ашаганда аякларын селкеп утыруның тәрбиясезлек икәнлеген төшендерү. | Әти-әниләр өчен мәгълүмат "Йогышлы авырулар"<br>Әңгәмә " Юына белү" 66б.(5) |

| | | | |
|---|---|---|---|
| Декабрь | Чаңгыда йөрергә, таудан чана шуарга, өч тәгәрмәчле велосипедта йөрергә өйрәтү. | | |
| Январь | Шартлар булган очракта балаларны коендыруны оештыру.<br><br>Айга 1 мәртәбә, 15-20 минутлык хәрәкәтле ял вакыты (физкультурный досуг) оештыру. | | Рәсемнәр буеча әңгәмә "Минем өем"<br>Уен "Алсу нинди кием киеп йөри" 440б.(7)<br>Д/у " Тапкыр җәяүле" 21б.(8)<br>Табышмаклар.<br>Шигырь " Юынырга кил мәче" 11б.(9)<br>Әңгәмә  "Табын янында матур утыру әдәбе" 68б.(6) |
| Февраль | Физик күнегүләр белән кызыксынуны тәрбияләү. | | Әти-әниләр өчен мәгълүмат "Юл йөрү кагыйдәләре"<br>Рәсем карау  "Без юынабыз".<br>Шигырь "Су" 31б.(4)<br>Уен "Без ничек киенәбез" 250б.(7) |
| Март | | | Әңгәмә "Табиб -безнең турыда кайгыртучы" 73б.(5)<br>Уен " Яшелчәләр" 262б.(7)<br>Рәсемнәр буеча әңгәмә " Җиләкләр"<br>Уен " Курчакны чишендерү" 20б.(6)<br>Шигырь "Гөлсөя" 91б.(4) |
| Апрель | | | Әти-әниләр өчен мәгълүмат "Гигиена кагыйдәләре"<br>Әңгәмә: "Сәламәтлек-зур байлык" 50б.(6)<br>Шигырь "Алсу" 76б.(9)<br>Уен " Ни өчен кирәк" 49б.(9)<br>Әти-әниләр өчен консультация "Өйдә Һава чистамы?" |

| | | | |
|---|---|---|---|
| Май | | | Шигырь "Ул шуңа кеченә" 60б.(4), " Тәти кул" 61б.(4) Уен"Сүзләр чылбыры" 259б.(7) Әти-әниләр өчен консультация . |

## *Танып белү. Иң гади математик кузаллауларын үстерү*

**Максат**: Танып белү, логик фикер йөртү, игътибар, хәтер үстерү. Күплек сан, зурлык, форма турында күзаллау булдыру. Мөстәкыйльлек, сабырлык тәрбияләү.

| *Ай* | *тема* | *максат* |
|---|---|---|
| Сентябрь | Адаптация чоры | Математик үсеш дәрәҗәсен күзәтү, тикшерү, әзерлекләрен формалаштыру; кыюлык тәрбияләү, шөгыльләрдә катнашу, җавап бирү теләге уяту |
| | Адаптация чоры | Аерым предметларны төркемләү һәм төркемнән бер предметны аерып алу ысуллары белән таныштыру; "күп", "бер", "берәү дә юк" сүзләрнең мәгънәләрен өйрәтү. |
| | Шар, куб | Балаларны шар( шарик), куб (кубик)ны аера һәм әйтә белүләрен ныгыту; төс, форма, зурлык төшенчәләрен кабул итәргә әзерләү. |
| | "Зур", "Кечкенә". | "Зур" һәм "кечкенә" төшенчәләрен кулланып төрле зурлыктагы предметларны үлчәү күнекмәләрен ныгыту; җылы,салкын, каты, йомшак төшенчәләрен кабул итә торган шартлар булдыру. |
| Октябрь | "Бер","Күп","Аз". | "Бер", "күп", "аз" сүзләрен кулланып предметларның санын аерырга өйрәтүне ныгыту. |
| | Предметларны төркемләү | Аерым предметларны төркемләү һәм төркемнән бер предметны аерып алу ысуллары белән таныштыру; "күп", "бер", "берәү дә юк" сүзләрнең мәгънәләрен өйрәтү. |
| | Түгәрәк | "Ничә?" соравыны җавап бирү өчен "бер", "күп", "берәү дә юк" сүзләрен кулланырга өйрәтү; түгәрәк белән таныштыру.Түгәрәкне тотып карау юлы белән дә тикшерү. |
| | Зур һәм кечкенә түгәрәк | Түгәрәкләрне размерлары буенча чагыштыру; зур түгәрәк һәм кечкенә түгәрәк төшенчәләрен куллану; түгәрәкне тотып карау юлы белән характерлы билгеләрен әйтү. |

| | | |
|---|---|---|
| Ноябрь | "Озын", "Кыска" | Озынлыгы буенча ике предметны чагыштырырга өйрәтү; предметларны чагыштыруның төрле ысулларын өйрәтүне дәвам итү.Тотып карау юлы белән предметларның билгеләрен әйтергә өйрәтү. |
| | "Бер", "Күп" | Билгеле урыннан бер яки күп предметны таба белергә; "күпме?" соравына җавап бирә белергә өйрәтү; озын(рак), кыска(рак)сүзләрен куллану күнекмәләрен үстерү; күзаллауны үстерү. |
| | Квадрат | Квадрат белән түгәрәкне аерырга өйрәтү; тәрбияче соравы буенча рәсемдә бу фигураларны күрсәтергә өйрәтү; бер һәм күп предметларны аерып күрсәтә алуга ирешү; зурлыгы, формасы буенча предметларны аера алу күнекмәләрен үстерү. |
| | Квадрат һәм түгәрәк | Билгеле төркем арасыннан бер һәм күп предметларны күрсәтү; квадрат белән түгәрәкне аера белергә өйрәтүне дәвам итү; форма, зурлык, төс турында белемнәрен үстерү. |
| Декабрь | "Озын", "Кыска" | Озынлыгы буенча ике предметны чагыштыру күнекмәләрен ныгыту; чагыштыру нәтиҗәләрен "озын-кыска", "озынрак-кыскарак" сүзләре белән билгеләргә өйрәтү. |
| | Квадрат һәм түгәрәк | Түгәрәк һәм квадратны аера һәм атый блү күнекмәләрен ныгыту; озынлыгы буенча ике предметны чагыштыра белү күнекмәләрен, бер һәм күп предметны күрсәтә белү күнекмәләрен ныгыту. |
| | Бертигез | Ике төркем предметларны чагыштырырга өйрәтү. ”Күп”, “Бертигез” сүзләрнең мәгнәсен аңларга өйрәтү. Уң һәм сул кулларны аера белүдә күнектерү. Балаларның игътибарын үстерү. |
| | Бертигез | Ике төркем предметларны чагыштырырга өйрәтүне дәвам итү. Ике предметны озынлыгы буенча чагыштырырга һәм “озынрак- кыскарак” сүзләре белән әйтеп бирә белергә кәнектерү. Балаларның кабул итү сәләтен үстерү. |
| Январь | “Киң”, “Тар” | Киңлекләре төрле булган ике предметны чагыштырырга өйрәтү. ”Киң”,”тар”, ”киңрәк”, ”таррак” сүзләрне кулланырга өйрәтү. Тәрбияче күрсәтмәләрен үтәүдә күнектерү. |
| | “Киң”, “Тар” | Киңлеге буенча ике предметны чагыштырырга өйрәтү; ике төркем берүк предметларны чагыштыру күнекмәләрен ныгыту.Түгәрәк һәм квадратны аера белү күнекмәләрен ныгыту. |
| | Өчпочмак | Өчпочмак белән таныштыру, атый һәм аера белергә өйрәтү; ике төркем предметларны чагыштыру һәм ”бертигез”, “шулкадәр үк” сүзләрне куллана белү |

| | | |
|---|---|---|
| | | күнекмәсен ныгыту, Балаларның кабул итү сәләтен һәм күзәтүчәнлеген үстерү. |
| | Шулкадәр | Ике төркем предметларны чагыштыра белүгә күнектерү; өчпочмак беән таныштыруны дәвам итү. Балаларның кабул итү сәләтен игътибарын үстерү. |
| Февраль | Геометрик фигуралар | Ике төрле төркем предметларны чагыштыру күнекмәләрен ныгыту. Түгәрәк, квадрат өчпочмакны аера һәм атый белергә өйрәтү; Пространствода ориентлашу күнекмәләрен ныгыту. |
| | "Биек", "Тәбәнәк" | Биеклеге буенча ике прдметны чагыштырырга өйрәтү, пространствода ориентлашырга өйрәтүне дәвам итү. Балаларның тыңлый белү осталыгын үстерү. |
| | "Биек", "Тәбәнәк" | Ике предметны биеклеге буенча чагыштырырга өйрәтүне дәвам итү. Ике төркем предметларны чагыштыру, "бертигез", "шулкадәр"сүзләр белән билгеләргә өйрәтүне дәвам итү. |
| | "Күбрәк", "Әзрәк" | Ике төркем предметларны чагыштырырга өйрәтү; "күбрәк", "әзрәк" сүзләрен куллана белергә өйрәтү. Предметларны биеклеге буенча чагыштыра белү күнекмәсен ныгыту. Балаларның кызыксынучанлыгын үстерү. |
| Март | "Күбрәк", "Әзрәк" | Ике төркем предметларны күплеге буенча чагыштырырга өйрәтүне дәвам итү. Түгәрәк, квадрат, өчпочмакны аера белү күнекмәләрен ныгыту. Балаларның игътибарын, хәтерен үстерү. |
| | "Күбрәк", "Әзрәк" | Берүк һәм аермалы ике төркем предметларны чагыштырырга өйрәтүне дәвам итү. Биеклеге хәм озынлыгы буенча ике предметны чагыштыруда күнектерү. Балаларның сенсор тою һәм кабул итү сәләтен үстерү. |
| | Чагыштыру | Ике төркем предметларны чагыштыру ысулларын өйрәтүне дәвам итү. Тәүлек өлешләрен аера һәм әйтә белергә күнектерү. Балаларның кабул итү сәләтен үстерү. |
| | Чагыштыру | Ике предметны озынлыгы һәм киңлеге буенча чагыштыру ысулларын өйрәтүне һәм нәтиҗәне тиешле сүзләр белән атый белү күнекмәләрен ныгыту. Геометрик фигураларны аера белүдә күнектерү. |
| Апрель | Шулкадәр | Бирелгән аваз яки үрнәк буенча тиешле санда предметлар сайлый белергә өйрәтү. Таныш геометрик фигураларны аера белүдә күнектерү. Балаларның уңай эмоцияләрен үстерү. |

| | | |
|---|---|---|
| | Шулкадәр | Бирелгән аваз яки үрнәк буенча тиешле санда предметлар сайлый белергә өйрәтү. Зурлыгы буенча ике предметны чагыштыру күнекмәләрен ныгыту. Сорауларга җавап бирү осталыгын үстерү. |
| | Бер, күп | Бер һәм күп хәрәкәтне аера белергә, “бер”, ”күп” сүзләрен куллана белергәөйрәтү. Пространстводагы юнәлешләрне аера белүдә кнектерү. Блалалрның истә калдыру сәләтен үстерү. |
| | Бер, күп | Бер һәм күп хәрәкәтне аера белергә өйрәтүне дәвам итү. Тәүлек өлешләрен аера белү күнекмәләрен үстерү. Балаларның тыңлап утыру һәм истә калдыру сәләтен үстерү. |
| Май | Кабатлау | Ике бертөрле һәм аермалы төркем предметларны чагыштыруда күнектерү; ике предметны зурлыгы буенча чагыштыруда күнектерү. |
| | Геометрик фигуралар | Геометрик фигураларны аера белү күнекмәләрен үстерү, балаларның күзәтүчәнлеген үстерү. |
| | Предметларны төркемләү | Уртак билгесе буенча предметларны төркемнәргә аеру күнекмәсен ныгыту. Соруларга җавап бирү осталыгын үстерү. |
| | Кабатлау | Ел буена өйрәнгән алынган белем һәм күнекмәләрне кабатлау. |

### *Аралашу ( сөйләм телен үстерү)*

**Максат:** өлкәннәр һәм үзара ирекле аралашырга, сүзләрдәге барлык сузык һәм тартык авазларны ачык итеп әйтә белергә өйрәтү.

| *Ай* | *тема* | *максат* |
|---|---|---|
| Сентябрь | " Танышу" | Яңа сүзләр белән таныштыру***: исемең, синең, минем, ничек;*** балаларның татар телен белү дәрәҗәсен ачыклау. |
| | " Танышу" | Балаларның татар телен белү дәрәҗәсен ачыклау эшен дәвам итү; Яңа сүзләр белән таныштыру***: бу, малай, кыз, курчак, менә.*** |
| | Без татарча сөйләшәбез | Яңа сүзләр белән таныштыру***:исәнмесез, сау булыгыз, рәхмәт, курчак;*** балаларда татар телен өйрәнүгә кызыксыну уяту. |
| | Без татарча өйрәнәбез | Балаларда татар телен өйрәнүгә кызыксыну уяту эшен дәвам итү; яңа сүзләр хисабына балаларның сүзлек байлыгын арттыру |

| | | |
|---|---|---|
| Октябрь | Уенчыклар | Яңа сүзләр белән таныштыру***:биредә, сикерә, бии***; уенчыкларның исемнәрен дөрес әйтергә өйрәтүне дәвам итү; Бу нәрсә?, Нишли? сорауларына җавап бирә белүне ныгыту. |
| | Уенчыклар | Уенчыкларның исемнәрен дөрес әйтергә өйрәтүне дәвам итү; тоемлап карау юлы белән уенчыкны танып әйтү: уенчыклар турында булган белемнәрен ныгыту, уенчыклар турында шигырьләр тыңлау. |
| | Уенчыклар | Яңа сүзләр белән таныштыру***:котлыйм, мә, ал, рәхим итегез.*** Сөйләмдә әйбрләрнең сыйфатын әйтергә һәм аларны күплек санда куллана белергә өйрәтү. |
| | Уенчыклар | Рәсемгә карап хикәяләүгә өйрәтүне дәвам итү. Балаларда татар теленә мәхәббәт, бер-берсенә ихтирам тәрбияләү. |
| Ноябрь | Уенчыклар | Яңа сүзләр белән таныштыру***:зинһар өчен, рәхмәт, бир әле, һәм.***Тәрбияче әйткән сүзләрне, кыска җөмләләрне балаларның кабатлап әйтә белүләренә ирешү. |
| | Уенчыклар | Үткән дәрестә өйрәнгән фразаларны истә калдыру эшен дәвам итү. Тәрбияче үрнәгендә җөмләләрне кабатлап әйтә белергә өйрәтүне дәва итү. |
| | Гаилә | Яңа сүзләр белән таныштыру***:әби-дәү әни, бабай-дәү әти, укый, бәйли,*** сүзләрне яңгырашы буенча аера белергә өйрәтү; [ә],[а] авазларының артикуляциясен ачыклау. Кем? Нишли? сорауларына җавап бирергә өйрәтү, балалар фольклорына кызыксыну уяту. |
| | Гаилә | Кем? соравына татар телендә бары тик кешеләргә карата гына әйтелүен; Нишли? соравы ярдәмендә эш-хәрәкәтне белдергән сүзләрне аера белүне ныгыту. |
| Декабрь | Купшы чыршы | Сузык һәм тартык авазларны ачык әйтергә күнектерү; сорауларга җавап бирү осталыгын, игътибарны үстерү; табигатькә соклану хисләре тәрбияләү. |
| | Куян чыршы янында | Сөйләмдә бәйлек сүзләрне кулланырга; кайда? кая? соравына җавап бирергә өйрәтүне дәвам итү; игътибарны үстерү; нәфис сүзгә кызыксыну тәрбияләү. |
| | Песи белән кәҗә чыршы янында | Балаларны тәрбияче соравына җавап бирергә өйрәтүне дәвам итү; сөйләмдә фигыльләр һәм сыйфатлар куллануны активлаштыру; игътибар, кабул итү сәләтен үстеү; хайваннарга карата шәфкатьлелек тәрбияләү. |

| | | |
|---|---|---|
| | "Тылсымлы"таяк | Аерым сүзләрне ачык итеп әйтергә өйрәтү; төсләр турында кузаллауны үстерү; балаларның кабул итү сәләтен, ишетү осталыгын үстерү; бергәләп шөгыльләнү теләге уяту. |
| Январь | Кошлар | Балаларны аваз ияртемнәрен дөрес итеп әйтергә өйрәтү; гомумиләштерүче сүзләрне куллануда күнектерү; кош исемнәрен, гәүдә өлешләрен өйрәнүне дәвам итү; хәтер сөйләм үстерү. Кошларга карата кайгыртучанлык тәрбияләү. |
| | Юлны чистартабыз | Балаларның кыш һәм кыш көне башкарыла торган хезмәт күнекмәләре турындагы белемнәрен формалаштыру. Сүзлекне активлаштыру, сүзләрне ачык әйтүдә күнектерү. Зурларга ярдәм итү һәм гади хезмәт хәрәкәтләре үтәү теләге тәрбияләү. |
| | Ж.Тәрҗемановның "Йокы бабай" әкияте | Әкиятнең эчтәлеген аңлап кабул итүләренә ирешү; балаларның игътибарын үстерү, сорауларга дөрес җавап бирү омтылышы уяту. |
| Февраль | Д/у "Шундый ук предметны тап" | Үз фикерләрен грамматик яктан дөрес итеп җөмлә төзеп әйтергә өйрәтү. Предмет исемнәрен атау хисабына сүзләрне активлаштыру. Игътибар, сенсор тою сәләтен үстерү. Гигиена күнекмәләре тәрбияләү. |
| | Машина һәм самолет | Балаларны өлешләрен, төсен, формасын аерырга һәм атарга өйрәтү; сузык авазларны әйтүдә күнектерү. Нинди?, Кайда?, Нәрсә? сорауларына җавап бирү осталыгына ирешү. Шофер, очучы һөнәрләренә хөрмәт тәрбияләү. |
| | Мәрьямне табыйк | Балаларны Кайда?, Кая? сорауларына җавап бирергә, сөйләмдә: өстенә, артына, астына сүзләрен кулланырга өйрәтү. Балаларның игътибарын хәтерен үстерү.Уенга кызыксыну тәрбияләү. |
| | Кына гөле | Балаларны бүлмә гөле-кына Һәм аның өлешләре белән таныштыру. Балаларның зурлар белән аралашуын, күзәтүчәнлекләрен үстерү. Бүлмә гөлләренә карата кызыксынучанлык, аларны тәрбияләү теләге уяту. |
| Март | Әнием-кадерлем | Гаилә лексикасын ныгыту, диагностик сөйләмен активлаштыру; әти-әнине ярату хисе тәрбияләү; өлкәннәргә булышу теләге уяту. |
| | "Чуар тавык" әкиятен уку | Әкиятне тыңлау теләге тудыру.Тәбияче башлаган җөмләне дәвам итү осталыгын, хәтерне, игътибарны, кабул итү сәләтен үстерү. Әкият персонажларына карата кызыксыну тәрбияләү. |

| | | |
|---|---|---|
| | "Йомры икмәк" рус халык әкиятен уку | Әкиятнең эчтәлеген аңларга ярдәм итү, сорауларга җавап бирү осталыгына өйрәтү. Балаларның активлыгын, игътибарын үстерү. Әкият белән кызыксыну. |
| | Бармак уены :"Йорт хайваннары" уен күнегүе | Халык аваз иҗаты белән таныштыруны дәвам итү. Йорт хайваннарының исемнәрен ныгыту хисабына сүзлеген активлаштыру; хәтер, кабул итү сәләтен үстерү. |
| Апрель | Бүлмә гөләре (фикус, яран) | Балаларның гади сорауларга җавап бирү осталыгын камилләштерү, бүлмә гөлләренең өлешләрен өйрәтү. Өлкәннәргә гөлләрне карарга ярдәм итү теләге тәрбияләү. |
| | Йөк машинасы | Машинаның өлешләре турында балаларның белемнәрен арттыру. Кызыксынучанлык, кабул итү сәләте үстерү. Тәрбияче һәм яшьтәшләре белән аралашу теләге тәрбияләү. |
| | Язгы урман | Кайда?, Нинди? соравына җавап бирергә өйрәтү. Ел фасылларына бәйле табигатьтәге үзгәрешләр турындагы белемнәрне формалаштыруны дәвам итү. Табигать объектларына карата сакчыл караш тәрбияләү. |
| | Кошлар | Яңа сүзләр белән танышуны дәвам итү; кошларның гәүдә өлешләре турында өйрәтүне дәвам итү. Күзәтүчәнлек, фикерләү сәләтен үстерү. Кошларны ярату хисе тәрбияләү. |
| Май | Балалар бакчасы ишегалдында | Исемнәр, фигыльләр, сыйфатлар хисабына сүз байлыгын үстерү; төсләрне, матурлыкны белдерүче сыйфатлар ярдәмендә сөйләм теленең компонентларын үстерү. |
| | Кызыксынучан тел | Балаларны [т ] [д ],[к ] [к,] авазлары кергән аваз ияртемнәрен әйтергә өйрәтү. Сөйләм үстерү, балаларның фантазиясен баету. Игътибарлылык тәрбияләү. |
| | Зоопарк | Җылы якта яшәүче хайваннар белән таныштыру, сөйләмдә берлек һәм күплек саннарда кулланырга өйрәтүне дәвам итү. Балаларның кабул итү сәләтен, игътибарын үстерү. Җылы як хайваннарына карата мәрхәмәтлелек тәрбияләү. |
| | Рәхмәт җәй | Яшелчә, җиләк-җимешләр, агачлар турында белемнәрен киңәйтү. Табигатькә карата сакчыл караш тәрбияләү. |

# *Танып белү.( Әйләнә тирә белән танышу)*

**Максат:** Әйләнә-тирә мохит, предметлар, табигать белән таныштыру. Яратырга, сакларга, аңларга, сокланырга өйрәтү. Әхлакый аңлы, иҗади фикер йөртүче шәхес тәрбияләү.

| *ай* | *тема* | *максат* |
|---|---|---|
| Сентябрь | Исәнмесез! | Исәнләшү, аралашу, үз-үзләрен тотуның иң гади кагыйдәләре белән таныштыру; зурлар, яшьтәшләр белән аралашу күнекмәләрен үстерү, әдәплелек,әхлаклылык сыйфатлары тәрбияләү. |
| | Көз безгә нәрсәләр бүләк итә. | Ел фасыллары турында белемнәрен киңәйтү, көз фасылының төп билгеләре (көн болытлы, вак яңгыр ява, яфрак коела, көннәр суыта) турында белемнәрен үстерү. |
| | Сап-сары яфраклар өзелеп төшә җиргә | Көзге агачларга хас булган билгеләр белән; чәчәкнең төзелеше: тамыр, сабак, яфрак, чәчәк таҗлары белән таныштыру; табигатькә мәхәббәт, кайгыртучанлык тәрбияләү. |
| | Безнең бүлмәдәге уенчыклар | Төркемдәге уенчыкларның исемнәре белән таныштыру; аларны ни өчен кирәк булуына, төсенә, формасына карап төркемнәргә аеру; уенчыклар белән сак уйнарга, дус, тату булырга өйрәтү. |
| Октябрь | Төркемебезнең куркынычсызлыгы | Төркем турында белемнәрен ныгыту; ориентлашу күнекмәләре үстерү, төркемдә булган әйберләргә сак караш тәрбияләү. |
| | Кояш кайда йоклый | Тере булмаган табигатькә: кояш, ай, йолдызларга карата кызыксыну уяту; табигатьтә булган бәйләнеш: кояш булса-көн, ай һәм йолдызлар булса -төн җитүе турында белемнәрен үстерү, киңәйтү. |
| | Песи һәи песи баласы | Йорт хайваннары һәм аларның балалары белән таныштыру; балаларның исемнәрен истә калдыру; йорт хайваннарына карата мәхәббәт тәрбияләү, алар турында кайгырту. |
| | Җиләк-җимешләр | Җиләк-җимешләр турында белемнәрен ныгыту; алардан нинди ризык әзерләп булуы турында фикер алышу. Кунакчыллык сыйфатларын тәрбияләү, төрле эшләрдә өлкәннәргә булышу теләге уяту. |

| | | |
|---|---|---|
| Ноябрь | Минем әти һәм минем әни | Гаилә турында күзаллау үстерү, гаилә әгъзәларын атый белергә өйрәтү, якыннарга карата ярату кайгырту хисләре тәрбияләү. |
| | Җил | Табигатьтәге бәйләнешне ( көз җитү, кояш аз җылыта, җил исә, агачлардан яфраклар коела) күрә белергә өйрәтү. Ишетү һәм күрү игътибарын үстерү. |
| | Җәнлекләр кышка ничек әзерләнә? | Табигатьтәге сезонлы үзгәрешләр арасындагы гади бәйләнешләрне билгеләргә өйрәтү; җәнленкләрнең үз-үзләрен тотышы, балалары турында белемнәрен үстерү. Игътибарлылык, дустанә мөнәсәбәт тәрбияләү. |
| | Төшке ашка безгә нәрсә? | Табак-савытны кулланышы ягыннан бүләргә өйрәтү (төсе, формасы,з урлыгы). Үз-үзеңне тоту кагыйдәләрен тәрбияләү. |
| Декабрь | Электр лампасы белән таныштыру | Электр турында балаларга гади төшенчә бирү; балаларның игътибарын, хәтерен ток белән бәйләнешле булган куркынычсызлык кагыйдәләрен балаларга җиткерү. Сакчыллык тәрбияләү. |
| | Гирлянда | Балаларга гирлянда турында башлангыч белемнәр бирү; электр тогы турындагы күзаллауларын ныгыту, төсләрен таный һәм аера белергә күнектерү. Сүз байлыгын киңәйтү. Күмәк эшчәнлектә катнашу теләге тәрбияләү. |
| | Яшел чыршы | Балалар белән бергә чыршыны карау. Яңа ел бәйрәме турында күзаллау киңәйтү һәм баету. Матурлыкны күрә һәм аңа соклана белү хисләре, чыршы уенчыкларына карата сакчыл караш тәрбияләү. |
| | Без музыка залында | Чыршы бәйрәменә әзерләнү: балаларны музыка залының бизәлеше, чыршы уенчыклары, аларның төсе, формасы белән таныштыру. Сүзлек активлаштыруны дәвам итү. |
| Январь | Ап-ак кар ява | Балаларны кар һәм аның үзлекләре (ак төстә, эри, йомшак, салкын, җиңел) белән таныштыру; тәрбияче сорауларына җавап бирергә күнектерү. Кышкы табигатькә соклану хисе, бергәләп уйнау теләге тәрбияләү. |
| | Алсу урамга җыена | Балаларның кышкы киемнәр турында белемнәренә төгәллек кертү, урамга чыкканда киенү эзлеклеген һәм киемнәрен истә калдырырга өйрәтү, башкаларга ярдәм итү теләге булдыру, киемнәргә сакчыл караш тәрбияләү. |

| | | |
|---|---|---|
| | Ләйлә суыктан курыкмый (рәсем буенча) | Рәсемне карарга, рәсемдәге предметларны танырга, исемнәрен дөрес әйтергә өйрәтү. Рәсем эчтәлеге буенча сорауларга җавап бирергә күнектерү. Сюжетлы рәсемнәр карарга теләк уяту. |
| | Күгәрченнәр, чыпчыклар-безнең нәни кошчыклар | Мәйданчыктагы җимлеккә килгән кошларны күзәтү. Исемнәрен әйтү. Балаларның игътибарын күзәтүчәнлеген , сорауларга җавап бирү осталыгын үстерү. Кошлар турында кайгырту, аларга ярдәм итү теләге уяту. |
| Феврвль | Безнең апа (тәрбияче ярдәмчсенең хезмәтен күзәтү) | Тәрбияче ярдәмчесе хезмәте белән бәйле эш-хәрәкәтләрне әйтергә өйрәтү, сүзлекне активлаштыру. Биремнәрне үтәү осталыгына ирешү. Кешеләр хезмәтенә кызыксыну тәрбияләү. |
| | Алсу бәйрәмгә җыена | Өс киемнәре аларның төсе һәм материалы белән таныштыруны дәвам итү; сүзлекне активлаштыру. Балаларның фикерләвен, соруларга җавап бирү, осталыгын үстерү. Курчаклар белән уйнарга теләк уяту, сакчыл караш тәрбияләү. |
| | Безнең әтиләр | Балаларны әтиләр хезмәтенә кагылышлы сюжетлы рәсемнәр карарга, эчтәлеген аңларга өйрәтү. Балаларның игътибарын, хәтерен үстерү.Төрле һөнәр кешеләренә һәм әтиләр хезмәтенә карата кызыксыну уяту. |
| | Кыргый хайваннар | Аю, бүре, куян, төлке, керпе, тиен сүзләрен сөйләмдә куллану һәм аларга хас билгеләрен әйтергә күнектерү. Балаларның җөмлә төзеп сөйли белүләренә ирешү; әкиятләр белән таныштыру. |
| Март | Безнең әниләр | Балаларны әниләр һөнәренә кагылышлы сюжетлы рәсемнәрнең эчтәлеген аңларга өйрәтү, эш- хәрәкәтне белдерә торган сүзләр хисабына сүз байлыгын киңәйтү. Кабул итү сәләтен үстерү. Әниләр хезмәтенә карата кызыксыну, хөрмәт тәрбияләү. |
| | Матрешкалар | Балаларны халык иҗат иткән уенчыклар белән таныштыруны дәвам итү. Сүз байлыгын киңәйтүһәм активлаштыру. Сорауларга җавап бирү осталыгын үстерү. Халык иҗатына кызыксыну тәрбияләү. |
| | Э. Шарифуллинаның" Иң матур әни” шигырен уку | Шигъри әсәрне тыңларга өйрәтүне дәвам итү. Балаларның игътибарын кабул итү сәләтен |

| | | |
|---|---|---|
| | | үстерү. Әниләргә карата ихтирам, ярату хисләре тәрбияләү. |
| | Ш. Маннурның "Яратам" шигырен уку | Шигырьнең эчтәлеген аңлап кабул итү сәләтен үстерү. Әти-әниләргә, туганнарга мәхәббәт тәрбияләү. |
| Апрель | Яз, яз килә | Балаларга язгы күренешләр турында башлангыч белемнәр (кар эри, тамчы тама, кояш җылыта) бирү.Сүз байлыгын киңәйтү һәм активлаштыру. Балаларның күзәтүчәнлеген үстерү. Табигатьтәге язгы күренешләр белән кызыксындыру. |
| | Җәнлекләр урманда яшиләр | Җәнлекләр турында балаларның белемнәрен киңәйтү һәм ныгыту; җәнлекләрне таный һәм исемнәрен атый белергә өйрәтү. Балаларның диалогик сөйләмен активлаштыру, фикерләвен үстерү. Җәнлекләр белән кызыксындыру. |
| | Сыерчыклар карлыгачлар килде | Балалары үзләренә таныш кошларның исемнәрен әйтергә өйрәтү, сүз байлыгын арттыру. Игътибарны, күзәтүчәнлекне, тәрбияче белән аралашу осталыгын үстерү. |
| | Песиле тал бөреләрен карау | Балаларны песиле тал, аның өлешләре белән таныштыру. Табигатьтәге язгы күренешләр турында белемнәр формалаштыруны дәвам итү. Балаларның кабул итү сәләтен, хәтерен, күзәтүчәнлеген үстерү. Табигать белән кызыксыну, соклану хисе тәрбияләү. |
| Май | Тузганак чәчәген карау | Балаларны үсемлекләр белән таныштыруны дәвам итү.Тузганак чәчәген танырга, исемен әйтергә, төзелеше буенча аера белергә өйрәтү. Балаларның сенсор тою һәм кабул итү сәләтен үстерү. Табигать белән турыдан-туры аралашудан шатлык хисләре уяту. |
| | Йорт хайваннары | Балаларның йорт хайваннары турындагы белемнәрне киңәйтү, хайваннарның исемнәрен, хәрәкәтләрен әйтергә күнектерү. Мөстәкыйльлек һәм активлык күрсәтү теләген үстерү, йорт хайваннарына карата кызыксыну тәрбияләү. |
| | Балалар тавык һәм чебиләр ашата | Балаларны рәсемне карарга, эчтәлеге буенча соруларга җавап бирергә өйрәтү. Игътибарны, хәтерне, образлы фикерләүне үстерү. Йорт кошларына карата мәрхәмәтлелек тәрбияләү. |

| | | |
|---|---|---|
| | Ком һәм аның үзлекләре. | Балаларны комны тикшерегә, төсе буенча аның дымлылыгын билгеләргә өйрәтү.Сүз байлыгын киңәйтү, сенсор тою сәләтен үстерү. Ком белән уйнарга кызыксындыру. |

***Социальләштерү***

**Максат**: Социаль- иҗтимагый тәрбия турында беренче күзаллауны үзләштерү.

- Балаларда төрле уеннар белән төрле кызыксынучанлык тәрбияләү.
- Бер-берсе белән уртак тел табуларыны ирешү.

| ***Ай*** | ***Сюжетлы-рольле уенннар<br>Хәрәкәтле уеннар<br>Дидактик уеннар<br>Сәхнәләштерелгән уеннар*** | ***Балаларны бер-берсе белән уртак тел табарга, җылы мөнәсәбәттә була белергә өйрәтү.*** | ***Гаилә әгъзалары арасында булырга тиеш гомумкешелек кыймматләре-нең өстенлеге турында күзаллау булдыру.*** |
|---|---|---|---|
| Сентябрь | Диагностика<br>*С/р уен* “Гаилә”, ”Шифаханә”<br>*Д/уен* “Бу рәсемдә нинди төсләр кулланылган?” (7), ”Уенчыкны тап” (10), ”Бу кемнең баласы?” (7), ”Җиләк-җимешләр” (7), ”Бу хайван ничек кычкыры?” (7)<br>*Х/уен* ”Күрсәт әле үскәнем” (10), тат халык уены “Без,без,без идек...” (6), ”Песи һәм тычканнар” (10), ”Мин куам син кач” (10).<br>*Сәхнәл.уен* “Йомры икмәк.” | Диагностика<br>“Болай ярый, болай ярамый” 92б. (11)<br>“Ялкау мәче” 114б. (11)<br>“Без шат балалар” уен (7) | Такмаклар 50 б. (12)<br>“Бармак” уеннары 51б. (12)<br>“Чылбыр” 259 б. (7) |
| Октябрь | *С/р уен* “Без шоферлар”, “Чәчтараш”<br>*Д/уен* “Туп нинди төстә?” (7) “Бу нинди яшелчә?”, “Бу кем?” (7), ”Бу нинди савыт- саба?” (7).<br>*Х/уен* “Флажокка кәдәр йогер” (10), ”Очты-очты” (12), ”Көн-төн” (12).<br>Бармак театры “Калач”<br>Курчак театры “Йокы бабай” | “Цирк” (5),<br>Әңгәмә: ”Ягымлы сүзләр” 22б. (5)<br>Әкият” Төлке, куян һәм әтәч” 55 б. (11) | Ситуация “Курчак Алсу нәрсә онытты?” 4б. (3)<br>“Чәбәкәй” 16-17б. (4) |

| | | | |
|---|---|---|---|
| Ноябрь | *С/р уен* “Автобус” (8), ”Әни-кыз”, ”Өйле”, ”Курчакны юындырабыз”<br>*Д/уен* “өс, баш, аяк киемнәре” (7), ”Күрсәт әле үскәнем” (10), ”Рәсемдә нәрсәләр ясалган?” (7), ”Бу нәрсә?” (7).<br>*Х/уен* “Җил исә”, “Ак куян” (10) | “Кабартма” (Ак калач) уены (7).<br>“Әйе-юк” (7).<br>*Д/уен* “Мин күрсәтәм, сез әйтегез” (3). | Әңгәмә: ”Исемең матур” 25б.(5)<br>“Бармак” уеннары (7).<br>“Күрсәт әле үскәнем” (7) |
| | *С/р уен* “Аш бүлмәсе”,”Туган көн”.<br>*Д/уен* “Җәяулеләр” (8), ”Бу нинди транспорт?” (8), ”Кушканны үтә (7), ”Моны кая кияләр?” (6)<br>*Х/уен* “Көн-төн” (10), ”Чеби белән песи” (10), “Очты-0чты” (10) | *Д/уен* “Серле сандык” (7)<br>Уен “Марат монда кил” 33б. (6)<br>*Х/уен* “Карусель” (11)<br>Әңгәмә “Уйнарга яратабыз” 43б. (5). | *Д/уен* “Мин әйтәм син тап” (7).<br>*Х/уен*”Аюлар һәм балалар” (11)<br>“Бармак” уеннары |
| Декабрь | *Күләгә театры* “Кәҗә бәтиләре һәм бүре”<br>*Курчак театры* “Өч аю” | “Карусель”(11)<br>“Тынлык уены” (11) | |
| Январь | *С/р уен* “Супермаркет”, “Тәмле” ”ЮХИДИ”.<br>*Д/уен* “Бу кайчак була?” (7), ”Җылы-суык” (7), ”Уенчык нинди?” 34б. (6), ”Тәрҗемәче” 8б. (3)<br>*Х/уен* “Җил исә”, ”Кем юк?”, ”Кем тизрәк”, ”Кошлар”.<br>*Бияләй театры* “Шалкан”. | Ситуация “Дустыңа шар бир”<br>“Чылбыр” 6б.(3) | “Бармак”уеннары.<br>Уен “Син кемне яратасың?” 9б. (3) |
| Февраль | *С/р уен* “Курчакның туган көне”, ”Курчакны юындырабыз”<br>*Д/уен* “Чыршы бизәү” 18б. (3), ”Мин күрсәтәм сез әйтегез” (7) ”Нинди?” 37б. (6)<br>*Х/уен* “Светофор” 27б.(11), ”Үз төсеңне тап” (10), “Песи һәм тычканнар” (10), “Маэмай”(10)<br>“Башак” әкияте буенча өстәл өсте театры. “ Кәҗә бәтиләре һәм бүре” өстәл өсте театры. | Уен “Үзеңне макта” (3).<br>Җырлы биюле уен “Парлашып калу” (13).<br>Уен “Киеменнән таны” (7). | “Гаилә чәчәге” уены 94б. (13).<br>“Бармаклар” уеннары. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| Март | *С/р уен* “Шифаханә” “Машиналар төзекләндерү станциясе”.<br>*Д/уен* “Рәсемне ясап бетер” 14б. (3), “Автобусны ясап бетер”, “Төсне тап”, ”Бу әйбер нигә кирәк?” (7), “Мин әйтәм, син тап” 40б.(6)<br>*Х/уен* “Машина һәм чыпчыклар”, “Трамвай” (10), ”Әбәкле”, ”Энә, җеп, төен” (10), ”Куык” (11).<br>*Өстәл театры* “Йомры икмәк” | Уен “Чәбәкәй” (4)<br>Уен ”Эндәшмә” (11)<br>Балаларны уенга җыю өчен күнегүләр “Уңган балалар” (11) | “Бармак” уеннары (4).<br>*Д/уен* “Бу кем?”, “Кем юк?” 41б.(6) |
| Апрель | *С/р уен* “Кибет”, “Уенчыклар кибетендә”.<br>*Д/уен* “Тамчы там” 29б.(3), ”Әйе- юк” (7). Табышмаклар, “кирәкле сүзен әйт” 20б.(3), ”Кия сала” (7).<br>*Х/уен* “Аю-бүре”, ”Ал кирәк-гөл кирәк” (10),”Куышлы”, “Үз төсеңне үзләп тап”<br>*Сәхнәл.уен* “Чыпчыклар һәм песи”. | Уен “Иптәшеңне сыйла”, ”Ак калач” уены. Җырлы биюле уен “Минем күлмәгем матур” 20б.(3) | Табышмаклар.<br>*Д/уен* “Нишли?”. |
| Май | *С/р уен* “Әнигә булышабыз”, ”Кунак көтәбез”, “Савыт-саба кибете”<br>*Д/уен* “Күбрәк-әзрәк” (7), “Охшаганмы -юкмы?” (7), “Шулай буламы-юкмы?” (11), Дөрес светофорны эзләп тап” (8), “Үз парыңны тап” (7).<br>*Х/уен* “Тигез юл буйлап”, “Мәче Һәм тычканнар”, “Үз төсеңне тап”, “Трамвай”, ”Инеш аша үтәбез” (10). | Уен “Курчак өчен бүләкләр сатып алу” 89б. (13), “Ак калач” 90б. (13) | “Бармак” уеннары (7), “Серле тартма” (7), “Гаилә чәчәге” уены 94б.(13). |

***Хезмәт***

**Максат:** хезмәткә карата уңай караш тәрбияләү:

- Хезмәткә катнашу теләге уяту.

- Өлкәннәргә ярдәм итү теләге уяту, эш нәтиҗәләренә сак караш тәрбияләү.
- Гади хезмәт күнекмәләре үстерү

| *Ай* | *Кул эше-конструкцияләү* | *Үз-үзеңә хезмәт күрсәтү. Хуҗалык көн күреш хезмәте* | *Табигатьтәге хезмәт.* |
|---|---|---|---|
| Сентябрь | **Тема:** Биек йорт һәм баскыч.<br>**Максат:** Биеклек һәм төс аңлатмаларын ныгыту; ничек төзүләре турында сөйләргә, үрнәк буенча төзәргә өйрәтү; төзелеш детальләрен таный һәм әйтә белү осталыкларын үстерү. | Үз-үзеңә хезмәт күрсәтү. Билгеле бер тәртиптә мөстәкыйль бауларын чишү һәм бәйләү) өйрәтү. Киенергә, чишенергә (кием кию, аны салу, төймәләрне чишү, төреп яки элеп кую, ботинкаларның бауларын чишү һәм бәйләү) өйрәтү. | Мәйданчыкта (участок) коелган яфраклар һәм башка төр чүп чарларны җыю, юлларны кардан чистарту, тәрбияче белән берлектә эскәмиядән карны себереп төшерү һ.б.<br>чарларны җыю, юлларны кардан чистарту |
| | **Тема:** Биек йорт һәм баскыч.<br>**Максат**: Корылма үрнәкләрен анализларга: төп өлешләрен аера һәм зурлыклары , формалары буенча таный белергә өйрәтү; төзелеш детальләре белән таныштыруны дәвам итү; төзелеш детальләре белән сак уйнарга (авызга капмаска) өйрәтү.<br>Тема: Биек йортлар һәм баскычлар.<br>Максат:Төрле төстәге детальләрдән файдаланып, корылмалар төзергә өйрәтү; аерым өлешләрнең бер берсенә карата пространствода торышын (йорт стеналры, түбәсе) ачыкларга өйрәтү. | Балаларны пөхтәлеккә, киемнәрендәге җитешсезлекләрне күреп һәм өлкәннәр ярдәме белән аны бетерергә өйрәтү.<br>Балаларны гади генә эшләрне, кушкан йомышларны мөстәкыйль рәвештә башкарырга күнектерү: шөгыльләр өчен материаллар тарату (тартма белән карандашлар, пумала, әвәләү өчен такта һ.б.) уйнап бетергәч уенчыкларны, төзү материалларын урынына җыеп кую. | Табигать почмагында һәм мәйданчыкта үсемлекләр һәм хайваннарны карауда катнашу теләге тәрбияләү. Өлкәннәр булышлыгы белән хайваннварны (балык, кошларны) ашатырга, бүлмә гөлләренә су сибәргә, яфракларның тузаннарын сөртергә, чәчәкләр үстерергә, туган утыртырга, түтәлдәге үсемлекләргә су сибәргә, ячелчәләр җыярга өйрәтү. |
| Октябрь | **Тема**: Юллар<br>**Максат:** төрле озынлыктагы юлларны төзергә, корылманы киңлеккә, озынлыкка мөстәкыйль үзгәртергә өйрәтү; төсе зурлыгы буенча предметларны туры китереп сайлый белү күнекмәләрен ныгытырга; өлкәннәр тормышына һәм хезмәтенә кызыксыну уяту. | Төркем бүлмәсендә тәртип һәм чисталык сакларга, бу эштә өлкәннәр кушканны үтәргә өйрәтү. Өлкәннәргә ярдәм итү теләге уяту, эш нәтиҗәләренә сак караш тәрбияләү. | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | **Тема**: Йомры икмәк өчен юл<br>**Максат**:Озынлык һәм төс турында белемнәрен ныгыту. | | |
| Ноябрь | **Тема**:Курчакка җиһаз<br>**Максат:**Үрнәк буенча төзү күнекмәләре бирү; сөйләп бирә белергә өйрәтү. | | |
| | **Тема**:Капка<br>**Максат**:Төзелешне биеклеккә үзгәртү; детальләрнең исемнәрен атарга өйрәтү. | | |
